**СОВЕТ
ПЕТРОПАВЛОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Ленина, д. 33
с.Слобода Петропавловская,423198

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ПЕТРОПАВЕЛ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
Ленин урамы, 33
Петропавловка бистәсе авылы, 423198

тел.: (8-4348) 3-35-41, факс: (8-4348) 3-35-18.Ppav.Nsm@tatar.ru

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы
Петропавел авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

2021 елның 5 нчеиюле № 13-38

Муниципаль районның җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрне (вәкаләтләрнең бер өлешен) тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Петропавел авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы Советына Петропавел авыл җирлеге Советына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының түбәндәге вәкаләтләрен тапшыру турындагы мәсьәләне карарга тәкъдим итәргә:

- авыл җирлегенең генераль планнарын, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау, авыл җирлегенең генераль планнары нигезендә әзерләнгән территорияне планлаштыру буенча документларны раслау, авыл җирлегенең шәһәр төзелеше проектлауның җирле нормативларын раслау.

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимне кабул иткән очракта, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Петропавел авыл җирлеге Советына:

әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы белән килешү төзергә;

әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында бюджет законнары нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Петропавел авыл җирлеге Советының 2021 елга һәм 2022, 2023 елларның план чорына Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Петропавел авыл җирлеге бюджеты турындагы карарга үзгәрешләр кертү турындагы карары проектын эшләргә һәм карарга тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru, Яңа Чишмә муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ruбастырырга (халыкка игълан итәргә).

4.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Петропавел авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Петропавел авыл җирлеге башлыгы Д.С.Никитин